

**/Укучылар иҗаты/**

## Авыл кышы

Авыл кышы… тып-тын, салмак кышкы әкият. Күк йөзеннән бик әкрен генә ап-ак канатлар кебек кар бөртекләре коела. Алар җиргә төшкәч, бөтен дөньяны йомшак, пөхтә кар юрганы белән каплыйлар. Өйләрнең түбәләре, агачларның ботаклары, хәтта урамдагы эскәмияләр дә – барысы да ак төскә күмелә.

Көннәр кыска, ә төннәр озын. Кич җиткәч, тәрәзәләрдә утлар кабына. Җылы утлар авылны тагын да серле итә. Шатланып куясың! Монда бит тормыш бара! Тәрәзәләреннән ут балкыган өйдә хәзер гаилә кичке ашка әзерләнәдер. Әниләре саф һавага тәмле коймак исе чыгара-чыгара плитә янында йөридер. Балалар аны сырып алып ашарга көтәләрдер. Ә тышта салкын. Шуңа да тәрәзәдәге утлар рәхәтлек бирә дә инде. Алар, утлы күзләр кебек, тыштагы салкынга каршы торалар. Тәрәзә пыялаларына кышкы бизәкләр төшкән, алар нәфис, челтәрле, кабатланмас бизәкләр.

Аһ, ул кышның һавасы! Ул бигрәк тә саф һәм хуш исле! Сулыш алган саен, күкрәк киңәя, бөтен тәнеңә җиңеллек килә. Таң атканда, кояш алтын нурларын сибә. Кар өстендәге һәр кар бөртеге җемелдәп, төрле төсләргә кереп ялтырый башлый. Мин шул вакыттагы матурлыкны гел фотога төшерергә яратам. Кечкенә генә матурлыкны да югалтасы килмичә, телефоныма җыеп барам.

Урамда, бигрәк тә яр буенда, балаларның шат авазлары ишетелә. Алар чанада таудан шуалар, кар бәрешәләр, кар өемнәре ясыйлар. Кышкы уеннардан соң, бит очлары аллана, күзләрендә очкыннар уйный. Тик мондый күренешләр бик сирәк була шул. Без хәзер тауны нинди дер вакытны күңелле уткәрә торган урынга да санамыйбыз бугай.


Кичке тынлыкта ерактан ук аяк тавышлары ишетелә. Авылдашларым кышкы кичтә урамда йөри. Үзләрен күрмәсәң дә, кар сөйли моны безгә, чөнки ул шыгырдый. Мондый терапия кая бар инде тагын. Авыл ул – үзе дәва, авыл ул – тынычлык урыны. Авыл кышы – табигать белән бердәмлек, күңелгә дәва, җанга азык. Кайтыгыз әле авылга, кар җырын тыңлап, туып үскән авыл урамнарын урарсыз.

***Настя Сафеева, VIII сыйныф укучысы***

**/Күңелле тәнәфес/**

### Кышкы кроссворд

1 - Кышта үзенчәлекле формаларга әверелә торган су пары.
2 - Ел фасылы, көздән соң килә.
3 - Кышкы ай.
4 - Яңа ел символы булган агач.
5 - Суның каты хәле.
6 - Кышын таудан шуу өчен җайланма.
7 - Кыш бабай дусты.
8 - Кышкы явым-төшем.
9 – Бозда шуу җайланмасы.
10 - Кышкы бәйрәм.



**/Авылым истәлеге/**

Балалар һәм яшүсмерләр өчен хәрәкәтле уеннардан да файдалырак шөгыль бармы икән? 1950 еллар ахырында төшерелгән менә бу фотода авыл балалары һәм яшьләренең башлангыч мәктәп мөдире Исмәгыйлев Хәлиулла бабай җитәкчелегендә чаңгы ярышына чыкканлыгын күрәбез. Ә бит ярыш өчен яраклы спорт киемнәре дә юк. Чаңгылары каен агачыннан, таяклары да чикләвек куагыннан. Шуңа да карамастан, кышның тәмен, балачакның кадерен белеп, үзләренә кызык ясый белгәннәр.



**/Котлыйбыз!/**



Декабрь аенда дөньяга килгән дустыбыз ***Гафиятуллина Руфинәне*** (IVсыйныф) туган көне белән котлап, ныклы сәламәтлек, укуында зур уңышларга ирешүен телибез.

**Газетаны гамәлгә куючы – Түбән Майна урта мәктәбе**
**Мөхәррир – Фәнүзә Гафиятуллина**
**Редколлегия әгъзалары – Асия Нурматова, Кәүсәр Насыйрова, Ләйсән Закирова, Настя Сафеева.**

# Мәктәп хәбәрчесе

**№10**
**(№71)**
**декабрь 2025 ел**

***Түбән Майна урта мәктәбе газите***

**Тел. 8 (84344) 4-38-46** **sch1644maina@mail.ru**

**/ Мөгаллим киңәше/**




## Ятлау – баш миенә гимнастика

Мәктәптә шактый еллар эшләү дәверендәге күзәтүләрдән чыгып, бер кыенлык турында язасым килә. Кемгәдер авыр проблема кебек тә түгелдер, әмма безне, укытучыларны, бу һичшиксез уйландыра торган мәсьәлә. Укучыларның текстан өзек, шигырь ятлау, кагыйдә, теорема, иң гадие һәм кирәклесе дә булган тапкырлау таблицасын да ятларга теләмәүләре – безне борчуга сала.

Аңлыйм, хәзер бөтен нәрсә кесәбездә, кулыбызда йөри. Сорасаң теләсә нинди сорауларыңа җавап бирә торган тартмабыз да бар. Хәзер инде инша язып та азапланырга түгел. Ясалма интеллект моны бик тиз эшләп бирә. Әмма, нинди генә мөмкинлекләр булмасын, без укучыларны башы яхшы эшли торган, уңышлы шәхес итеп тәрбиялисебез килә. Шуңа да мәктәп программасында "ятлау" дигән биремнәр кертелгән.

Мәктәптә укытыла торган фәннәр һәрберсе үзенчә корылган инде. Ләкин кагыйдә, теорема, терминнар, текстлар ятлау күпчелек фәннәрнең программаларында бирелгән. Ана теле һәм әдәбият укытучысы буларак шуңа басым ясыйсым килә. Ятлау - кешенең фикерләү сәләтен үстерүдә, хәтерен ныгытуда, сүз байлыгын арттыруда гаять мөһим роль уйный. Бу процесс сүзләрнең мәгънәсен тирәнрәк аңларга, образлы фикерләргә һәм телнең музыкаль яңгырашын тоярга ярдәм итә. Шигырь ятлаганда, без авторның уй-кичерешләренә, дөньяга карашына якынаябыз, аның белән бергә дулкынланабыз. Бу балалар өчен аеруча файдалы. Ул аларның тел үсешен, хәтерен, игътибарлылыгын һәм башка бик күп кирәкле сыйфатларын үстерә. Шигырьләр ярдәмендә балалар әйләнә-тирә дөньяны танып белә, әхлакый кыйммәтләрне үзләштерә һәм үз фикерләрен матур итеп белдерергә өйрәнә. Моннан тыш, шигырь ятлау балаларның сәнгатькә, әдәбиятка мәхәббәтен уята. Еллар узган саен, шигырьләрне ятлау әһәмиятен югалтмый. Киресенчә, мәгълүмат технологияләре үскән заманда, шигырьләр безгә рухи багланышны сакларга, хисләребезне ачыкларга һәм тормышның мәгънәсен тирәнрәк аңларга ярдәм итә.

Шигырь ятлау – вакытлы күңел ачу гына түгел, ә шәхеснең рухи үсешенә зур өлеш кертүче әһәмиятле эш. Аның файдасы моның белән генә чикләнми. Шигырьләрне тавыш белән укыганда, без дөрес интонацияне, басымны һәм әйтелешне үзләштерәбез. Бу исә үз фикерләребезне төгәл һәм ачык итеп җиткерү өчен кирәк. Шулай ук, шигырь ятлау башкалар алдында чыгыш ясаганда ышанычны арттыра, аудитория белән аралашуны җиңеләйтә.

Ятлау – ул акыл өчен гимнастика кебек, аның эшчәнлеген яхшырта, яңа нейрон бәйләнешләр тудыра һәм булганнарын ныгыта. Бу процесс хәтерне үстерүдә генә түгел, ә уйлау тизлеген арттыруда, иҗади сәләтләрне ачуда һәм фикерләү күләмен киңәйтүдә дә зур роль уйный. Теоремалар ятлау абстракт уйлауны үстерә, логик фикерләүне яхшырта һәм проблемаларны чишү сәләтен арттыра. Математик формулаларны һәм кагыйдәләрне хәтердә саклау интеллектуаль эшчәнлекне көчәйтә, анализ ясау һәм нәтиҗә ясау сәләтен камилләштерә. Бу алым фәнни өлкәдә генә түгел, ә көндәлек тормышта да уңышлы карарлар кабул итүгә ярдәм итә.

Гомумән алганда, текстларны ятлау – рухи үсешкә зур өлеш кертүче мөһим күнекмә. Ул хәтерне ныгыта, уйлауны тизләтә, иҗади сәләтләрне ача һәм тел осталыгын үстерә. Шуңа күрә төрле текстларны ятлауга вакыт табу һәркем өчен дә файдалы.

Ятлата алмыйм, диеп ишетелгән зарлардан соң туган фикерем бу минем, хөрмәтле укучылар, әти-әниләр. Ятлау биремнәренә игътибарлы булсагыз иде. Югарыда санап кителгән файдалы үзлекләренә күз йоммасагыз иде. Мондый күнекмәләрне ешрак эшләп, балабызның төрле яктан үсешен генә тәэмин итәбез. Алдагы елларда бу өй эше бала белән укытучы арасында каршылык тудырмый иде. Ә хәзер өй эшенә ятларга бирелсә, баланың бөтенләй кәефе кырыла. Ул мондый төр өй эшләрен тау күчерергә кушкандай кабул итә. Аралашу аз булган чорда сөйләм күнекмәләрен шактый гына яхшырта алыр идек. Бергәләп тырышканда гына авыр эшләр җиңеллек китерер.

***Фәнүзә Гафиятуллина, татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

## Икенче чирек нәтиҗәләре

**/Рәсми хәбәрләр/**

Бу чирек мәктәп укучылары һәм укытучылары өчен киеренке, тыгыз шартларда үтте. Беренчедән, яртыеллыкка нәтиҗә ясалса, икенчедән, фән олимпиадаларының район турлары булып узды. Шуңа күрә, икенче чирек – өстәмә әзерләнүне таләп итә торган җаваплы чор ул. Шуның өстенә, Яңа ел бәйрәме дә тиздән килеп җитәчәк.

Олимпиадаларга чакырулы укучыларыбыздан VIII сыйныф укучысы **Закирова Ләйсән** – химиядән призер, татар һәм рус телләреннән – җиңүче булды. VI нчы сыйныф укучысы **Нурматова Асия** – татар теленнән, VIII сыйныфтан **Әхсәнова Мәдинә** – географиядән призер исеменә лаек булдылар. IX сыйныф укучысы **Вәлиева Мәрьям**– рус теленнән җиңүче булды.

Яңа ел алдыннан районда кышкы рәсемнәр буенча конкурс булып узды. Безнең укучылар да үзләренең иҗат җимешләрен тәкъдим иттеләр һәм призлы урыннарны яуладылар.**Нурматова Мәдхия** (III сыйныф) белән **Хәбибрахманова Хәнифә** (IX сыйныф)–I урынга, **Нурматов Яхъя** (IIсыйныф) белән **Нурматова Муаззама** (V сыйныф) II урынга, **Хәбибрахманова Асия** ( III сыйныф) белән **Гафиятуллина Руфинә** (IV сыйныф) III урынга лаек булдылар.

Чирек билгеләре буенча белем сыйфаты 52,26% тәшкил итте. Отличниклар **Гафиятуллина Руфинә**(IV сыйныф), **Закиров Инсаф** белән **Камалов Илнур**(V сыйныф), **Закирова Ләйсән**(VIII сыйныф), **Гафиятуллин Фаил**(IX сыйныф).

***Илдар Сафиуллин, уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары***




**/Безнең бәйрәмнәр/**

## Яңа ел – серле бәйрәм

Яңа ел ул бер могҗиза кебек. Сабыйлар күңеленең матурлыгы менә шушы гади дә, тылсымлы да рәсемнәрдә дияр идем. Һәр баланың Яңа елга үзенең өмете, хыялы бар. Алар бу бәйрәмдә әкият көтәләр, могҗизага ышаналар. Һәм бу ышаныч аларны чиста, саф күңелле итеп саклый.

Яңа елның сихрилеге сабыйларның бәйрәмгә аталап ясаган рәсемнәрендә аеруча ачык чагыла. Аларда дөньяның иң якты төсләре җыелган. Анда кызыл, яшел, зәңгәр, алтынсу төсләр бер-берсе белән үрелеп, күзләрне иркәли. Чыршы уенчыкларының ялтыравы, кар бөртекләренең нәфислеге, Кыш бабайның мәрхәмәтле йөзе – болар барысы да балаларның хыял дөньясыннан алынган кебек. Мин бу рәсемнәргә караганда, үзем дә бер мизгелгә балачакка әйләнеп кайткандай хис итәм. Күңелдәге барлык борчулар, мәшәкатьләр онытыла, урынына шатлык, өмет, бәхет хисләре тула. Әйтерсең лә, Яңа ел могҗизасы миңа да кагылды. Алар нинди күңел белән яшиләр, нәрсәгә ышаналар – безнең дә киләчәгебез шундый булачак. Бу рәсемнәргә карап, авторларның кулларыннан гөлләр тама дияр идем.



Хафизов Илдарлар гаиләсе белән иң зур кул эшләнмәсе ясаганнар. Бу адым-баланың хыялларын, җиңү максатын тормышка ашыру дигән кебек булды. Сезне дә, дусларым, Яңа елга аякка басу белән котлыйбыз. Сезгә сәламәтлек, тынычлык, озын гомер телибез. Яңа елда һәркемгә хәерле сәгатьтә хәерле эшләр насыйп итсен һәм уңышлар да сөендерсен.

Сәхнә бизәлеше дә гадәттәгечә матур иде: ялтырап торган чыршы, төрле төстәге уенчыклар, гирляндалар. Зал да бәйрәмчә бизәлгән, һәр җирдә Яңа ел рухы сизелеп тора. Балалар төрле җырлар җырладылар, шигырьләр сөйләделәр, биеделәр. Һәркем үзенең талантын күрсәтергә тырышты. Нәни дусларыбыз да сәхнәдә иң мавыктыргыч, иң кызыклы номерларны күрсәттеләр. Алар өчен мәктәп чыршысы бик зур булып күренгәндер инде. Шулай да сер бирмәделәр, өйрәнгән чыгышларын тамашачы яратып карады. Кыш бабай белән Кар кызы да балаларның күңелләрен ачты, аларга төрле уеннар уйнаттылар, табышмаклар әйттеләр. Тик әле сәхнәгә килгәнче алар үзләре дә төрле сынаулар уздылар. Каршылыкларны җиңеп килгән Кыш бабай балаларны шатландырып китәргә дә ашыкты. Тамашаның иң дулкынландыргыч өлеше, әлбәттә, бүләкләр өләшү булды. Кыш бабай һәр балага пакетлар тапшырды. Балаларның шатлыктан күзләре янды, алар бүләкләрен тизрәк ачып карарга ашыктылар.



Кичке бәйрәм дә күңелле тамаша арасында серле бүләкләр өләшү, лоторея уеннары белән үрелеп барды. Өлкән сыйныф укучылары үзләре әзерләгән бәйрәмне җирена җикереп алып та бардылар. Һәрберсенең өлеше кергән өстәл дә, концерт номерлары да сүз әйтерлек түгел иде. Бәйрәм ахырында барлык катнашучылар бергәләп Яңа ел җырын җырладылар. Һәр бала Яңа ел могҗизасына ышанган хәлдә таралышты. Мәктәптәге Яңа ел тамашасы онытылмаслык тәэсирләр калдырды.

***Гөлшат Закирова, V сыйныф җитәкчесе***



**/Мәктәп тормышы/**

## Декабрь аенда уздырылган чаралар

1 декабрьдә Хайваннарны яклау көне билгеләп үтелә. Бу көн – җәмгыятьнең игътибарын хайваннарның хокукларына, аларның яшәү шартларын яхшыртуга юнәлтү максатыннан үткәрелә торган халыкара чара. Һәрбер тереклек иясе яшәргә, сәламәт булырга һәм иминлектә гомер итәргә хокуклы. Кызганычка каршы, бүгенге көндә бик күп хайваннар кешеләрнең рәхимсез мөгамәләсенә дучар була. Аларны ташлыйлар, җәзалыйлар, кыйныйлар. Күп очракта хайваннарны коммерция максатларында кулланалар, аларның ихтыяҗларын бөтенләй исәпкә алмыйлар. Бу көнне билгеләп үтүнең максаты – кече туганнарыбызга карата мәрхәмәтле булырга, аларга ярдәм итәргә кирәклеге турында искә төшерү. Халыкка мәгълүмат җиткерү, җәмгыятьнең әхлакый кыйммәтләрен үстерү һәм хайваннарга карата җаваплы караш формалаштыру өчен бу көнне төрле хәйрия акцияләре, флешмоблар, семинарлар һәм башка чаралар оештырыла.

---



1 декабрьдә Русия математикларның һөнәри бәйрәме билгеләп үтелә. Математика көне – рус математигы, Евклид булмаган геометриягә нигез салучычы Николай Лобачевскийның туган көненә багышланган. Бәйрәм кысаларында бөтен ил буйлап мәгърифәтчелек һәм белем бирү чаралары уздырыла. Безнең мәктәптә дә укучылар өчен сыйныф сәгатьләре, викториналар, видеодәресләр үткәрелде.

---



Мәктәптә СПИДка каршы чаралар үткәрү – яшь буынны әлеге куркыныч авырудан саклауның иң мөһим юлларының берсе. СПИД – ул иммунитетны зарарлаучы вирус (ВИЧ) китереп чыгарган авыру. Ул организмны төрле инфекцияләргә һәм яман шеш авыруларына каршы тору сәләтеннән мәхрүм итә. Мәктәпләрдә СПИДка каршы чаралар комплексы укучыларга әлеге авыру турында мәгълүмат бирүне, аның таралу юлларын аңлатуны, профилактика чаралары турында сөйләүне үз эченә ала. Бу эш төрле формаларда алып барылырга мөмкин: лекцияләр, әңгәмәләр, тематик дәресләр, кинофильмнар карау, плакатлар һәм буклетлар тарату. СПИДка каршы чаралар үткәрүнең максаты – укучыларда сәламәт яшәү рәвеше күнекмәләрен тәрбияләү, наркотиклардан һәм башка зарарлы гадәтләрдән баш тарту, саклану чараларын куллану һәм үз сәламәтлекләренә карата җаваплы караш булдыру.

---

Билгесез солдат көне – илебез тарихындагы иң тәэсирле һәм мөһим даталарның берсе. Бу көнне без Ватан өчен гомерен биргән, ләкин исемнәре билгесез булып калган батырларыбызны искә алабыз. Бу көн – хөтер, рәхмәт, горурлык көне. Билгесез солдат көне – яшь буынны патриотизм рухында тәрбияләү өчен дә әһәмиятле. Бу көнне мәктәпләрдә төрле чаралар уздырыла. 3 декабрьдә без дә бу чараларга кушылдык.

5 декабрь – Геройлар көне. Бу көнне Ватан өчен гомерен биргән каһарманнарны искә алабыз, аларның батырлыгы алдында баш иябез. Геройлык – ул бер мизгелдә туа торган нәрсә түгел, ул күпьеллык тәрбия. Ватанга мәхәббәт хисе, кешелеклелек, гаделлек, кыюлык һәм җаваплылык нәтиҗәсе. Шулар турында укучыларга сөйләнелде.

Мәктәптә Россия Конституциясе көне – укучыларда ватанпәрвәрлек хисләрен тәрбияләү, дәүләтнең төп законына карата хөрмәт уяту өчен үткәрелә торган мөһим чара. Бу көнне төрле тематик дәресләр, сыйныф сәгатьләре, викториналар оештырылды. Аларда укучылар Конституциянең төзелеше, аның төп принциплары һәм кеше хокуклары турында мәгълүмат алды.

---



11 декабрьдә мәктәптә ГТО турында сөйләшү узды. ГТО – ул сәламәтлекне ныгыту, физик әзерлекне үстерү һәм гомумән алганда, сәламәт яшәү рәвешен алып бару өчен бик яхшы мөмкинлек диеп узды Рифкать абый Туктамышев. Сөйләшү барышында ГТО нормативларын тапшыруның уңай якларына аеруча басым ясалды. Беренчедән, ул сәламәтлекне ныгыта, чөнки даими рәвештә шөгыльләну организмның чыдамлыгын арттыра.

17 декабрьдә мәктәптә Түбән Новгород өлкәсенең Выкс шәһәренең "Яшьләр шәһәре" Бөтенроссия конкурсында катнашуына бәйле темага дәрестән тыш чаралар узды. Укучылар шәһәрнең тарихы, мәдәнияте һәм икътисады белән таныштылар, аның үзенчәлекләрен һәм перспективаларын өйрәнделәр. Дәресләр интерактив формада узды, балалар төрле уеннарда, викториналарда һәм дискуссияләрдә актив катнаштылар.

***Мәктәп тормышы вакыйгаларын редколлегия әгъзалары әзерләде***